**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» 2009 елның 29 июлендәге ПУ-393 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 29 февралендәге ПУ-159 номерлы, 2014 елның 17 мартындагы ПУ-279 номерлы, 2016 елның 14 маендагы ПУ-411 номерлы, 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-297 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы ПУ-189 номерлы һәм 2020 елның 30 мартындагы ПУ-218 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указда:

2 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

б) Указга кушымтаның 11 пунктында «(Казан, Түбән Кама, Идел буе, Чаллы, Көньяк-Көнчыгыш территориаль бүлекләре)» сүзләрен «(Кама аръягы, Казан, Идел буе, Көньяк-Көнчыгыш территориаль бүлекләре)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 29 май
№ ПУ-415